Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Шәле авыл җирлеге башлыгы
карары

26 сентябрь, 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Сорочьи Горы - Шали» автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документациясен (I, II этап) карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2017 елның 21 августындагы 15 номерлы, 2017 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 07 октябрендәге 52 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 57 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә, җирлектә яшәүчеләрнең Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Сорочьи Горы - Шали» автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документациясен (I, II этап) карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү билгеләргә (далее по тексу - документация по планировке территории).

2. Территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты – 2023 елның 12 октябрендә 10.00 сәг.;

3.2. үткәрү срогы - 1 көн;

3.3. үткәрелү урыны - Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле ав., Хәйруллин ур., 35 й. адресы буенча урнашкан Шәле авыл мәдәният йортының тамаша залы;

3.4. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле ав., Хәйруллин ур., 35 й. адресы буенча (дүшәмбе-җомга 09-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр).

4. Шәле авыл җирлеге халкына җиткерү максатыннан 2023 елның 6 октябрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитет бинасында, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле авылы, Хәйруллин ур., 35 йорт адресы буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә бер көнгә үзгәрешләр кертү проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештыру, (дүшәмбе-җомга 8-00 сәгатьтән 12-00 сәгатькә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

5. Территорияне планлаштыру документларын гавами тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынган затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитетына эш көннәрендә 8-00 сәг. 12-00 сәг. һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәг. 2023 елның 12 октябренә кадәр, 422796, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шәле авылы, Хәйруллин ур., 35) адресы буенча язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитетына:

6.1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Вперед» («Алга») район газетасында гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны бастырырга, Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга;

6.2. Территорияне планлаштыру документларын билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда карау буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. территорияне планлаштыру документлары белән алданрак Интернет челтәрендә Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре - Шәле авыл җирлеге» бүлегендә танышырга мөмкин.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы

И.Р. Ахметзянов